# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**(IV чакырылыш)**

Утыз тугызынчы утырыш

«09» июнь 2025 ел № 137 Олы Мишә ав.

Олы Мишә авыл җирлеге Теләче муниципаль район Советының 18.02.2011 № 10 «Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында "

Татарстан Республикасы Теләче районы прокуратурасының 28.03.2025 ел №02-08-01-2023/Прдп12-25-2090037 номерлы протестын карап, «Федераль закон "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында" Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Мишә авыл җирлеге Теләче муниципаль район Советының 18.02.2011 № 10 «Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында» карарына (Олы Мишә авыл җирлеге Советының 15.11.2013 № 104, 16.01.2015 № 158 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
– күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Олы Мишә авыл җирлеге Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексында 21 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «д» пунктчасы белән тулыландырырга:
«д) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләрдән тыш (алга таба - анкетадагы белешмәләр).».
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы Ф.Б.Җамалетдинов